| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2025 Кукмара ш. № 684

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 22 июнендәге 422 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының башлангыч гомуми, төп гомуми һәм (яисә) урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **карар бирәм:**

1. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 22 июнендәге 422 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының башлангыч гомуми, төп гомуми һәм (яисә) урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.5.2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.2.1. Оешмага муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен сорап гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә, оешма хезмәткәре гариза бирүчегә кәгазь вариантта муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирә. Гариза бирүче таләбе буенча кәгазьдә электрон документның нөсхәсе белән бергә аңа электрон документның нөсхәсе алынма мәгълүмат чыганагына яздырып бирелергә яки гариза бирүче

адресына электрон почта аша электрон документның нөсхәсе җибәрелергә мөмкин.

Балигъ булмаган затка карата муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен балигъ булмаган затның гариза бирүче булып торучы законлы вәкиле алганда, балигъ булмаган затка карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләрен алу хокукын гамәлгә ашыру балигъ булмаган затның гариза бирүче булмаган законлы вәкиле тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин. Бу очракта балигъ булмаган затның законлы вәкиле булган гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаган затның балигъ булмаган затка карата тиешле хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алырга вәкаләтле башка законлы вәкиленең фамилиясен, исемен, әтисенең исемен (булган очракта), шәхесен таныклый торган документ турында белешмәләрне күрсәтә.

Балигъ булмаган затка карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләре, әгәр гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаган затка карата дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сорала торган нәтиҗәләрен шәхсән үзе алырга теләк белдергән булса, балигъ булмаган затның башка законлы вәкиленә бирелә алмый.

Әлеге пунктча белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне Оешма эшчәнлеге регламентында билгеләнгән срокларда чират тәртибендә башкарыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**